**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2021 ел, 22 декабрь №52

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Иске Йомралы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июнендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Иске Йомралы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Иске Йомралы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге адрес буенча урнашкан территорияләрне кабат зоналаштыру өлешендә:

1) Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Иске Йомралы авыл җирлеге (кадастр номеры 16:08:190102:536) Ж1 зонасыннан (индивидуаль торак төзелеше зонасы) СХ2 зонасына (авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары зонасы) (кушымта);

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Иске Йомралы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Йомралы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) А. М. Сафинга йөкләргә.

**Иске Йомралы авыл җирлеге Башлыгы**
**Иске Йомралы авыл җирлеге Советы Рәисе Р.А.Моратов**

Кушымта

